**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Хуҗәмәт торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

18 ноябрь 2025 № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Хуҗәмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге Хуҗәмәт торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Хуҗәмәт торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, СВОда катнашып һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Хуҗәмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Садовая урамындагы юлны ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Хуҗәмәт торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы З.Р.Мортазина